**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№2569**
**29.05.2020**

Яр Чаллы шәһәрендә территориаль иҗтимагый үзидарә системасын үстерүгә юнәлдерелгән чараны үткәрүгә территориаль иҗтимагый үзидарәләр рәисләренә компенсация түләүләрен гамәлгә ашыру өлешендә шәһәр бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78.1 статьясындагы 2 пункты, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт (муниципаль) учреждениеләре булмаган коммерцияле булмаган оешмаларга субсидияләр бирүне җайга салучы норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында» 2017 елның 7 маендагы 541 номерлы Карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Территориаль иҗтимагый үзидарә системасын үстерүгә юнәлдерелгән чараны уздыруга территориаль иҗтимагый үзидарә җитәкчеләренә компенсация түләүләрен гамәлгә ашыру өлешендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2019 елның 31 октябрендәге 988 номерлы Карары, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының «2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар план чорына Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты турында» 2019 елның 6 декабрендәге 34/5 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәрендә территориаль иҗтимагый үзидарә системасын үстерүгә юнәлдерелгән чараны үткәрүгә территориаль иҗтимагый үзидарәләр рәисләренә компенсация түләүләрен гамәлгә ашыру өлешендә шәһәр бюджетыннан субсидия бирү тәртибен кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның 2014 елның 3 декабрендә «Челнинские известия» газетасының 90 нчы санында басылып чыккан «Территориаль иҗтимагый үзидарәгә ярдәм күрсәтүгә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2014 елның 23 октябрендәге 6542 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның Үзәк районы хакимияте Башлыгы И.Н. Галимовка, Башкарма комитетның Комсомол районы хакимияте Башлыгы А.И. Кисловка, Башкарма комитетның Автозавод районы хакимияте Башлыгы В.Х. Харисовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы И.А. Сәгыйдуллинага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2020 елның 29 маендагы
2569 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәрендә
территориаль иҗтимагый үзидарә системасын үстерүгә юнәлдерелгән чараны үткәрүгә территориаль иҗтимагый үзидарәләр рәисләренә компенсация түләүләрен гамәлгә ашыру өлешендә шәһәр бюджетыннан субсидия бирү
тәртибе

1 бүлек. Субсидияләр бирү турында гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Территориаль иҗтимагый үзидарә системасын үстерүгә юнәлдерелгән чараны уздыруга территориаль иҗтимагый үзидарә җитәкчеләренә компенсация түләүләрен гамәлгә ашыру өлешендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2019 елның 31 октябрендәге 988 номерлы Карары нигезендә территориаль иҗтимагый үзидарәләр рәисләренә шәһәр бюджетыннан субсидия (алга таба – субсидия) бирү механизмын билгели.

2. Субсидия бирүнең максаты - территориаль иҗтимагый үзидарәләр рәисләренә компенсация түләүләрен гамәлгә ашыру өлешендә Яр Чаллы шәһәрендә территориаль иҗтимагый үзидарә системасын үстерү.

3. Субсидия әлеге тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен шәһәр бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә субсидия бирү турында килешү нигезендә «Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениесе (алга таба – Башкарма комитет) тарафыннан бирелә.

4. Субсидия алучылар категориясе – Яр Чаллы шәһәре территориясендә теркәлгән территориаль иҗтимагый үзидарәләр.

2 бүлек. Субсидия бирү шартлары һәм тәртибе

5. Килешү төзү планлаштырыла торган айдан алдагы айның беренче числосына яки хокукый акт белән билгеләнгән башка датага субсидия алучы яисә, чыгымнарны (алынып бетмәгән керемнәрне) кайтару тәртибендә субсидия бирүне җайга салучы хокукый акт белән килешү төзү каралмаган булса, субсидия бирү турында карар кабул итү туры килергә тиешле таләпләр:

1) субсидия алучының шәһәр бюджетына, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча срогы чыккан бурычлары һәм хокукый акт нигезендә субсидия бирү планлаштырыла торган шәһәр бюджеты алдында башка срогы чыккан бурычлары булмаска тиеш;

3) субсидия алучы үзгәртеп оештыру, ликвидацияләү процессында булырга тиеш түгел, аңа карата банкротлык процедурасы кертелмәгән, субсидия алучының эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылырга тиеш түгел.

6. Субсидия алу өчен субсидия алучы тарафыннан тапшырыла торган документлар исемлеге:

1) әлеге тәртипкә 1 нче кушымтада каралганча, шәһәр бюджетыннан субсидия алу өчен заявка;

2) гариза бирүченең (гариза бирүче вәкиленең) шәхесен таныклаучы документ күчермәсе;

3) вәкилнең вәкаләтләрен раслаучы документ (әгәр гариза бирүче исеменнән вәкил эш йөртсә);

4) гражданнарның гомуми җыелышының (конференциясенең) территориаль иҗтимагый үзидарә рәисен сайлау турында беркетмәсе;

5) территориаль иҗтимагый үзидарәнең оештыру документлары (юридик зат өчен - устав; Россия Федерациясе законнары нигезендә төзелгән юридик затның Россия Федерациясе территориясендә урнашкан урын буенча салым органында исәпкә кую турында таныклык; Бердәм дәүләт юридик затлар реестрына язма кертү турында таныклык);

6) бухгалтерлык балансы, финанс нәтиҗәләре турында хисап һәм аларга кушымталар – юридик зат өчен;

7) Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә;

8) шәһәр бюджетына, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән субсидияләр, бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча срогы чыккан бурычлар һәм шәһәр бюджетына башка срогы чыккан бурычлар булмау турында мәгълүматлар;

9) әлеге тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен башка норматив хокукый актлар яки муниципаль хокукый актлар нигезендә шәһәр бюджетыннан акчалар алу (алмау) турында мәгълүмат;

10) әлеге тәртипкә 2 нче кушымтада каралган форма буенча, субсидия бирелә торган елга эш планы.

7. Субсидия алучылар өчен аның күләме чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Территориаль иҗтимагый үзидарә системасын үстерүгә юнәлдерелгән чараны уздыруга территориаль иҗтимагый үзидарә җитәкчеләренә компенсация түләүләрен гамәлгә ашыру өлешендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2019 елның 31 октябрендәге 988 номерлы Карары нигезендә билгеләнә һәм шәһәр бюджетында исәпкә алына.

8. Башкарма комитетның финанс идарәсе, субсидия алучыларга компенсация түләүләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар керүне күздә тота торган шәһәр бюджеты турында Шәһәр Советы карары басылып чыккан көннән башлап өч эш көне эчендә, Яр Чаллы шәһәренең территориаль иҗтимагый үзидарәләре рәисләренә компенсация түләүләрен финанслау турында Башкарма комитет карары проектын әзерләүне гамәлгә ашыра.

9. Башкарма комитетның район хакимияте:

1) әлеге тәртипнең 8 пунктында каралган Башкарма комитет карары чыккан көннән башлап өч эш көне эчендә, шәһәрнең тиешле районы территориясендә теркәлгән территориаль иҗтимагый үзидарәләргә әлеге тәртипнең 6 пунктында каралган документларны тапшыру зарурлыгы турында хәбәр итә;

2) әлеге пунктның 1 пунктчасында каралган документларны алган көннән башлап җиде эш көне эчендә, әлеге тәртипкә 4 нче кушымтада каралган форма буенча субсидия бирү турында килешүне әзерли һәм имзалауны тәэмин итә.

10. Башкарма комитет Җитәкчесе ике эш көне эчендә субсидия бирү турында килешү проектын имзалый һәм аны теркәү өчен Башкарма комитетның тиешле район хакимиятенә җибәрә.

11. Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан субсидия бирү турындагы килешү проектын имзаланган көнне Башкарма комитетның тиешле район хакимияте аны терки һәм теркәлгән көннән башлап бер эш көне эчендә субсидия алучыга җибәрә.

12. Субсидия алучыга субсидия бирүдән баш тарту өчен нигез булып тора:

1) субсидия алучының әлеге тәртипнең 5 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки әлеге тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау (тулы булмаган күләмдә тапшыру);

2) субсидия алучы тарафыннан тапшырылган документлардагы мәгълүмат дөрес булмау.

13. Субсидия ай саен, субсидия бирү турында килешү, әлеге тәртипкә 3 нче кушымтада каралган форма буенча календарь ай эчендә башкарылган эш турында айлык хисап һәм әлеге тәртипкә 1 нче кушымтада каралган форма буенча финанслауны гамәлгә ашыру өчен ай саен бирелә торган заявка нигезендә, субсидия алучы тарафыннан кредит оешмаларында ачылган һәм субсидия бирү турындагы килешүдә күрсәтелгән исәп-хисап счетына күчерелә.

14. Субсидиядән файдалану нәтиҗәлелегенең күрсәткече булып, территориаль иҗтимагый үзидарә тарафыннан җирле әһәмияткә ия мәсьәләләр буенча үз инициативаларын гамәлгә ашыруга җәлеп ителгән гражданнар санының хисап елында тиешле территориаль иҗтимагый үзидарә эшчәнлек алып бара торган тиешле район территориясендә (күпфатирлы торак йорт подъездында, күпфатирлы торак йортта, комплекста) яшәүче гражданнарның гомуми санына карата мөнәсәбәте тора.

## 3 бүлек. Хисаплылыкка таләпләр һәм субсидия бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешенә контрольне гамәлгә ашыру турында таләпләр һәм аларны бозган өчен җаваплылык

15. Субсидия алучы, хисап елыннан соң килүче елның 01 февраленә кадәр срокта, Башкарма комитет адресына субсидия бирү турында килешү кушымтасында билгеләнгән форма буенча нәтиҗәлелек күрсәткечләренә ирешү турында хисап бирә.

16. Башкарма комитет субсидия бирү турындагы килешүдә субсидия алучы тарафыннан өстәмә хисап бирү срокларын һәм формаларын билгеләргә хокуклы.

17. Башкарма комитетның районнар хакимиятләре һәм Башкарма комитетның финанс идарәсе исеменнән Башкарма комитет субсидия алучы тарафыннан субсидиядән файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешү турында хисап тапшырылган көннән башлап 10 эш көне эчендә, субсидия алучы тарафыннан субсидия бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыра.

18. Башкарма комитет тарафыннан субсидия бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе бозылу һәм (яки) әлеге тәртипнең 14 пунктында каралган нәтиҗәлелек күрсәткечләренә ирешмәү ачыкланган очракта, өч эш көне эчендә субсидия алучыга ачыкланган бозулар турында белдерү кәгазе һәм субсидияне шәһәр бюджетына кире кайтару турында таләп җибәрелә.

Субсидия алучы, бозу очраклары турында белдерү кәгазен һәм субсидияне шәһәр бюджетына кире кайтару турында таләпне алган көннән башлап 15 эш көне эчендә, субсидияне кире кайтаруны гамәлгә ашыра.

19. Чираттагы финанс елының 1 гыйнварына торышы буенча, хисап финанс елында файдаланылмаган субсидиянең калганы, хисап елыннан соң килүче финанс елының беренче 15 эш көнендә шәһәр бюджетына кайтарылырга тиеш.

Хисап финанс елы – субсидия алучы әлеге тәртиптә каралган документларны Башкарма комитет адресына җибәргән ел.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова

Яр Чаллы шәһәрендә территориаль иҗтимагый үзидарә системасын үстерүгә юнәлдерелгән чараны үткәрүгә территориаль иҗтимагый үзидарәләр рәисләренә компенсация түләүләрен гамәлгә ашыру өлешендә шәһәр бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә 1 нче кушымта

Башкарма комитет
Җитәкчесе
_____________________________

Шәһәр бюджетыннан субсидия алу өчен
заявка

_________________________________________________________________________
(территориаль иҗтимагый үзидарәнең исеме)

Яр Чаллы шәһәрендә территориаль иҗтимагый үзидарә системасын үстерүгә ____________ сум күләмендә субсидия бирүегезне сорыйм.

| | | |
|---|---|---|
| 1 | Территориаль иҗтимагый үзидарә рәисенең Ф.И.А.и. | |
| 2 | Рәиснең ИНН | |
| 3 | Элемтә телефоны/факс | |
| 4 | Почта адресы | |
| 5 | Банк реквизитлары | |

Рәис Имза
Гариза бирү датасы
м.у.

Яр Чаллы шәһәрендә территориаль иҗтимагый үзидарә системасын үстерүгә юнәлдерелгән чараны үткәрүгә территориаль иҗтимагый үзидарәләр рәисләренә компенсация түләүләрен гамәлгә ашыру өлешендә шәһәр бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә
2 нче кушымта

Килештерелде:
________ район хакимияте Башлыгы
________________________________
________________________________
(дата)

Расланды:
ТИҮ рәисе
______________________
______________________
(дата)

______елга _______________ ТИҮ эш планы

| № т/б | Чараларның исеме | Үткәрү сроклары | Катнашучылар |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | | | |
| | | | |

Яр Чаллы шәһәрендә территориаль иҗтимагый үзидарә системасын үстерүгә юнәлдерелгән чараны үткәрүгә территориаль иҗтимагый үзидарәләр рәисләренә компенсация түләүләрен гамәлгә ашыру өлешендә шәһәр бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә
3 нче кушымта

Килештерелде:
________ районы хакимияте Башлыгы
___________________________________
___________________________________
(дата)

Расланды:
ТИҮ рәисе
_______________________
_______________________
(дата)

20___елның ____________ хисап чоры өчен башкарылган эш турында хисап

| № т/б | Территориаль иҗтимагый үзидарә эшчәнлеген бәяләү критерийлары | Чараларның исеме | Үткәрү датасы | Катнашучылар саны |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Халыкны территорияне төзекләндерү өлкәсендәге чараларны оештыруга һәм үткәрүгә, шул исәптән территориаль иҗтимагый үзидарә территорияләрен санитар чистарту һәм төзекләндерү буенча язгы, көзге айлыкларда катнашуга җәлеп итү | | | |
| 2. | Территориаль иҗтимагый җирле үзидарә территориясе чикләрендә гражданнар тормышы иминлеген күтәрү буенча, шулай ук территориаль иҗтимагый үзидарә | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | эшчәнлегенең башка мәсьәләләре буенча чараларда катнашу | | | |
| 3. | Яшәү урынындагы халык белән социаль-мәдәни, спорт, яшьләр һәм мәгълүмати-методик эш | | | |
| 4. | Торак хуҗалыкта җылылык һәм электр энергиясен, газ һәм суны югалтуларны киметүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру | | | |
| 5. | Халыкны территориаль иҗтимагый үзидарә территориясе мәсьәләләрен мөстәкыйль рәвештә хәл итүгә җәлеп итү | | | |
| 6. | Иҗтимагый үзидарә территорияләрен үстерү мәсьәләләре буенча иҗтимагый инициативалар саны | | | |

Яр Чаллы шәһәрендә территориаль иҗтимагый үзидарә системасын үстерүгә юнәлдерелгән чараны үткәрүгә территориаль иҗтимагый үзидарәләр рәисләренә компенсация түләүләрен гамәлгә ашыру өлешендә шәһәр бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә
4 нче кушымта

Шәһәр бюджетыннан субсидия бирү турында
килешү №________

Яр Чаллы шәһәре «____» __________ 2020

«Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениесе, алга таба «Башкарма комитет» дип аталучы, шәһәр Уставы нигезендә эш итүче Башкарма комитет Җитәкчесе ___________________ исеменнән, бер яктан, һәм _____________ территориаль иҗтимагый үзидарәсе, алга таба «Алучы» дип аталучы, Устав нигезендә эш итүче рәис ______________________ исеменнән, икенче яктан, бергә «Яклар» дип аталучылар, Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәренең территориаль иҗтимагый үзидарәсе рәисләренә компенсация түләүләрен финанслау турында» _________________ елның _____ номерлы карары нигезендә түбәндәгеләр турында әлеге Килешүне төзеделәр:

1. Килешү предметы

1.1. Әлеге килешүнең предметы булып, Башкарма комитет тарафыннан _______________________ территориаль иҗтимагый үзидарәсенә компенсация түләве өчен, аның рәисенә субсидия бирү тора.

1.2. Субсидия күләме елына ______________________ сум тәшкил итә.

Субсидияне финанслау, Алучы тарафыннан хисап аеннан соң килүче __________ числога кадәр срокта, субсидия алу өчен бирелә торган заявка (алга таба – заявка), календарь ай эчендә башкарылган эш турында хисап нигезендә, ай саен ____________________ сум күләмендә шәһәр бюджеты акчалары хисабына гамәлгә ашырыла.

2. Якларның хокуклары

2.1. Башкарма комитет хокуклы:

1) субсидия бирүнең билгеләнгән тәртибе нигезендә, Алучыдан башкарылган эш турында хисап сорарга һәм алырга;

2) субсидиядән максатчан файдалануны тикшерүне үткәрергә.

2.2. Алучы әлеге Килешү буенча субсидия алу, аннан файдалану тәртибенә Башкарма комитеттан аңлатмалар алу хокукына ия.

## 3. Якларның бурычлары

3.1. Башкарма комитет бурычлы:

1) субсидияне әлеге Килешүдә каралган тәртиптә һәм шартларда заявкада күрсәтелгән счетка күчерергә;

2) субсидия бирү шартларын һәм тәртибен тикшерүне гамәлгә ашырырга;

3) башкарылган эш турында хисапта күрсәтелгән дөрес булмаган мәгълүматлар факты ачыкланган очракта, алар ачыкланган көннән башлап 3 эш көне эчендә Алучыга субсидияне кире кайтару турында таләп җибәрергә.

3.2. Алучы бурычлы:

1) Башкарма комитетка, субсидиядән файдалану турында һәм календарь ай эчендә башкарылган эш турында хисапларны теркәп, заявка бирергә;

2) әлеге килешүгә кушымтада каралган форма буенча нәтиҗәлелек күрсәткеченә ирешү турында хисап бирергә;

3) башкарылган эш турында дөрес булмаган хисап бирелү ачыкланган очракта, Башкарма комитетның кире кайтару турында язмача таләбе Алучы тарафыннан алынган көннән башлап 5 эш көненә кадәр срокта субсидияне (яки аның өлешен) кире кайтарырга.

3.3.Алучы Башкарма комитетның тиешле район хакимияте һәм Башкарма комитетның финанс идарәсе тарафыннан субсидия бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен тикшерүләрне гамәлгә ашыруга риза.

3.4. Әлеге Килешүнең 1 пунктында күрсәтелгән субсидия бирүнең мәҗбүри шартлары булып түбәндәгеләр тора:

1) Алучының һәм әлеге килешү буенча йөкләмәләрне үтәү максатларында төзелгән килешүләр (килешенүләр) буенча тәэмин итүчеләр (подрядчылар, башкаручылар) булып саналган затларның (аларның устав (склад) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашындагы дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләрдән, шулай ук аларның устав (склад) капиталларында шундый ширкәтләр һәм җәмгыятьләр катнашындагы коммерцияле оешмалардан тыш) субсидия биргән бюджет акчаларын төп бүлүче (бүлүче) һәм дәүләт (муниципаль) финанс контроле органнары тарафыннан аларның субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүләрен тикшерүләрне гамәлгә ашыруга ризалыгы;

2) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә, югары технологияле чит ил җиһазлары, чимал һәм комплектлаштыру эшләнмәләре сатып алганда гамәлгә ашырыла торган операциялардән, күрсәтелгән юридик затларга субсидия бирүне җайга сала торган норматив хокукый актлар, муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән һәм әлеге акчаларны бирү максатларына ирешү белән бәйле башка операцияләрдән тыш, алынган акчалар хисабына чит ил валютасы сатып алуны тыю.

## 4. Якларның җаваплылыгы

4.1. Яклар әлеге Килешү буенча йөкләмәләрне үтәмәгән һәм (яки) тиешенчә үтәмәгән өчен Россия Федерациясе законнары һәм әлеге килешү шартлары нигезендә җаваплы.

## 5. Килешүнең гамәлдә булу вакыты

5.1. Әлеге килешү ____________ кадәр гамәлдә, ә әлеге килешү буенча кабул ителгән йөкләмәләрне үтәү өлешендә – алар Яклар тарафыннан тулысынча үтәлгәнче.

## 6. Йомгаклау нигезләмәләре

6.1. Әлеге Килешү Якларның килешүе яки граждан законнарында каралган нигезләр буенча суд карары нигезендә срогыннан алда өзелергә мөмкин.

6.2. Әлеге Килешүгә барлык үзгәрешләр һәм өстәмәләр язма рәвештә өстәмә килешүләр белән рәсмиләштерелә һәм ике Як тарафыннан имзалана.

6.3. Әлеге Килешү, һәр Як өчен берешәр итеп, бертигез юридик көчкә ия ике нөсхәдә төзелде.

## 7. Якларның юридик адреслары, реквизитлары һәм имзалары

Шәһәр бюджетыннан субсидия бирү турында «____» ________20____ елның №_______ килешүгә кушымта

Килештерелде:
________ районы хакимияте Башлыгы
___________________________________
___________________________________
(дата)

Расланды:
ТИҮ рәисе
_______________________
_______________________
(дата)

________________20____ елда нәтиҗәлелек күрсәткеченә ирешү турында хисап

| № т/б | Чараның исеме | Күрсәткечнең исеме | Нәтиҗәлелек күрсәткеченең плandaгы зурлыгы | Нәтиҗәлелек күрсәткеченең факттагы зурлыгы |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |